Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова шикаятьләренә бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2018 елның 14 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова шикаятьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Ике шикаять тә бер үк предметка кагылышлы булганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерде.

Докладчы судья А.Р. Шакараев мәгълүматын, яклар — гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты хокукый тәэмин итү бүлеге баш белгече Е.Н. Ситдыйкова, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты җир кишәрлекләренә хокукларны рәсмиләштерүгә аналитик ярдәм һәм социаль мәсьәләләр бүлеге башлыгы А.Р. Сафина аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең ярлыкау мәсьәләләре буенча секторы мөдире Д.А. Рослов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Ю.А. Старшая, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле —

Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге әйдәүче консультанты Р.Р. Мингалиев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләре белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты буенча гражданнарга индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яки яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлеген бушлай бирү, әлеге Тәртипнең II бүлегендәге 7 пункты белән каралган очрактан тыш, аларны җир кишәрлеген түләүсез алуга хокукы булган гражданнар исемлекләренә (алга таба шулай ук — исемлекләр) керткән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә башкарыла.

Күрсәтелгән Тәртипнең II бүлегендәге 7 пункты шуны билгели:

мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тартса яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тартса яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәсә, гаризага «Мөрәҗәгать итүче баш тартты» дигән статус бирелә; мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тартуы яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тартуы яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәве акт (2 нче һәм 3 нче кушымталар) һәм комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Шикаятьләрдән һәм аларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова — өч баласы булган күпбалалы аналар һәм җир законнары нигезендә алар дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән җир кишәрлеген милеккә түләүсез алу хокукына ия. 2013—2014 елларда гражданка О.Н. Меркурьева һәм гражданка Л.В. Рагимова әлеге хокукны тормышка ашыру өчен гаризалар биргәннәр һәм индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеген түләүсез алуга хокукы булган гражданнар исемлегенә кертелгәннәр.

Шул ук вакытта җир кишәрлекләре Татарстан Республикасы Җир кодексы нигезендә исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә тапшырылырга тиеш булуга карамастан, алар мөрәҗәгать итүчеләргә бирелмәгән. Аларның раславы буенча, Татарстан Республикасы Җир кодексы гражданнарга җир кишәрлекләрен чиратлылык тәртибендә бирү өчен күрсәтелгән срокны үтәмәүне аларның җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартуы яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килмәве белән бәйли.

Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының дәгъвалана торган нигезләмәләре исә гражданнарга җир кишәрлекләрен исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык

тәртибендә бирүдән баш тарту мөмкинлегенә алар җир кишәрлеген сайлап алудан бер мәртәбә баш тартканнан соң яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына бер мәртәбә килмәгәннән соң ук юл куялар. Шуның белән гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова фикере буенча, дәгъвалана торган нормалар фактта тәкъдим ителгән беренче сайлап алуда ук җир кишәрлегенә ризалашырга мәҗбүр итәләр, чөнки баш тарту шунда ук җирле үзидарә органын җир кишәрлеген бер ел эчендә бирү буенча гавами-хокукый бурычыннан азат итүгә китерәчәк.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүчеләр Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 38 (беренче һәм өченче өлешләр) статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; гаилә, ана булу, ата булу һәм балачак дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук

куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирүнең законда каралган срогын алар бер мәртәбә: җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тарткан яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тарткан яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәгән очракта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәмәс өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм җир законнары өлкәләренә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук җир законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясында каралганча, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә

торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла (2 өлеш); Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (5 өлеш).

Җир законнары Россия Федерациясе Җир кодексыннан, федераль законнардан һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан тора (Россия Федерациясе Җир кодексының 2 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы). Әлеге Кодексның 39.5 статьясындагы 6 пунктчасы белән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар милкенә вәкаләтле органның карары нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирелә дип билгеләнгән. Шул ук вакытта әлеге Кодекс, федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә һәм шуларны үтәү йөзеннән җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә җир хокукы нормаларын үз эченә алган актлар чыгара ала (2 статьяның 4 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты белән шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шәһәр округының муниципаль милкендәге мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү кертелгән. Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 статьясындагы 1 пунктчасы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының

2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 8 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты белән беркетелгән.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы 1 өлеше, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясындагы 1 өлеше белән үзара бәйләнештә 40 статьясындагы 2 өлешенең 4 абзацы буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба шулай ук — Башкарма комитет) муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнарының җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, башка федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән мәсьәләләрне хәл итү йөкләнгән Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы булып тора.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итеп, Башкарма комитет федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтләрне законлы рәвештә гамәлгә ашырган, әлеге вәкаләтләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) статьясына нигезләнгән, аның буенча җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга (алга таба шулай ук — күпбалалы гаиләләр) җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү оештыру-процедура механизмының конституциячеллеген тикшерү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. 2017 елның 26 декабрендәге 77-П номерлы карарында Татарстан Республикасы Конституция суды шуны күрсәтте: Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы өч һәм аннан күбрәк балалары булган

гражданнарның җир кишәрлеген түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыруга юнәлгән закон нормаларын үтәү буенча җирле үзидарә органнарының гамәлләре эзлеклелеген регламентлаштыра; шундый җир кишәрлекләрен бирү процедурасын билгеләү вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарына йөкләп, республика закон чыгаручысы моның өчен мәҗбүри булган шартларны ачык һәм төгәл билгеләгән.

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 13 пунктының беренче абзацы нигезендә өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарның аларга җир кишәрлекләрен шул исәптән индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен бирү хокукы, әлеге статьяның 15 пунктында каралган очраклардан тыш, алар индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеген алуга хокукы булган гражданнар исемлегенә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә тормышка ашырыла. 15 пункт, үз чиратында, вәкаләтле җирле үзидарә органы җир кишәрлекләре бирелүдә мәнфәгатьле гражданнарны күрсәтелгән исемлекләрдән төшереп калдыру һәм аларга җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карарны кабул итә торган очракларның тулы исемлеген билгели, алар исәбенә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында гражданнарның җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартуы яки аларның җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калуы керә (4 пунктча). Шуның белән, карала торган эш мөнәсәбәтендә, республика закон чыгаручысы күпбалалы гаиләләр җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә чакырылырга тиеш һәм, димәк, алар өч мәртәбә баш тартканнан соң яки өч мәртәбә килмәгәннән соң гына андый гаиләләр законда гарантияләнгән җир кишәрлеген милеккә түләүсез бер ел эчендә алу хокукын югалталар дип билгеләгән.

Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының дәгъвалана торган нигезләмәләре буенча өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре, шул исәптән индивидуаль торак төзелеше өчен, гаризага «Мөрәҗәгать итүче баш тартты» дигән статус

мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тартканда яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тартканда яисә андый процедурада катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәгәндә (алга таба шулай ук — мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сайлап алудан баш тартуы яки аның андый процедурада катнашуга килмәве) бирелү очрагыннан тыш, алар исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә бирелә. Тәртипнең I бүлегендәге 4 пунктка анализ күрсәткәнчә, ул үзенең максатчан билгеләнеше һәм хокукый мәгънәсе буенча да, эчтәлеге буенча да, җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләләргә исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча милеккә түләүсез бирелә дигән гомуми кагыйдәне беркетеп һәм сылтама рәвешендә әлеге кагыйдәдән чыгармага (Тәртипнең II бүлегендәге 7 пункты) күрсәтмә биреп, асылда Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 13 пунктының беренче абзацындагы (дәгъва белдерелә торган Тәртип кабул ителгән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) нигезләмәләрне кабатлый. Тәртипнең I бүлегендәге 4 пунктының турыдан-туры эчтәлегеннән күренгәнчә, Тәртипнең II бүлегендәге дәгъва белдерелә торган 7 пунктында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 15 пунктында (дәгъва белдерелә торган Тәртип кабул ителгән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) каралган кебек, күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча бирү мөмкин булмаган конкрет очрак билгеләнергә тиеш. Шул ук вакытта, карала торган хокукый җайга салу системасындагы урыныннан чыгып, Тәртипнең II бүлегендәге 7 пункты үзеннән-үзе җирле үзидарә вәкаләтле органының мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сайлап алудан баш тартуын яисә аның андый процедурада катнашуга килмәвен нинди формада теркәвен генә билгели торган процедур-процессуаль характердагы норма булып тора. Шуның белән әлеге пункт үзенең хокукый табигате буенча да, максатчан билгеләнеше буенча да Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты мәгънәсе буенча

аңа йөкләнгән регулятив функцияне башкара алмый. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 15 пункты (дәгъва белдерелә торган Тәртип кабул ителгән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) белән аналогия буенча 7 пунктта чагылыш табарга тиеш булган мәсьәлә Тәртипнең II бүлегендәге 9 пунктында җайга салынган, аның эчтәлегеннән аңлашылганча, күпбалалы гаиләләр җир кишәрлеген түләүсез алуга хокукы булган гражданнар исемлегеннән тәкъдим ителгән җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тартканнан соң яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килмәгәннән соң төшереп калдырыла.

Димәк, Тәртипнең I бүлегендәге 4 пунктында сылтаманың Тәртипнең II бүлегендәге 9 пунктына түгел, ә 7 пунктына булуы дәгъвалана торган нигезләмәләрне куллануга, шуның нәтиҗәсендә билгеләнгән срокта күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен күпбалалы гаилә бер мәртәбә дә, өч мәртәбә дә тәкъдим ителгән җир кишәрлеген сайлап алудан баш тарткан яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына килмәгән очракта бирмәүгә юл куя. Башка сүзләр белән әйткәндә, Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты белән билгеләнгән җайга салу аның формаль-юридик мәгънәсендә муниципаль дәрәҗәдә күпбалалы гаиләләрнең җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләрендә билгесезлек тудыра, чөнки мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә җир кишәрлеген сайлаудан баш тартуыннан яки андый сайлау процедурасына килмәвеннән соң ук җирле үзидарә органнары тарафыннан закон нигезендә билгеләнгән аннан соңга калмыйча күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирелергә тиешле еллык срокны үтәмәскә мөмкинлек бирә.

Россия Федерациясе Конституция суды берничә мәртәбә күрсәткәнчә, хокукый норма эчтәлегенең билгесезлеге аның бертөрле аңлашылуын тәэмин итә алмый, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен какшата, тигезлек һәм закон өстенлеге принципларын бозуга китерергә

мөмкин; хокукый нормалар билгелелек, ачыклык, мәгънә берлеге гомумхокук таләпләренә туры килергә тиеш, чөнки конституциячел тигезлек аларны барлык хокук кулланучылар тарафыннан бертөрле аңлау һәм аңлату шарты белән генә тәэмин ителергә мөмкин; шуңа күрә хокук кулланучы тарафыннан ирекле аңлатылуына китерә торган хокукый норманың билгелелеге таләбен бозу үзеннән-үзе мондый норманы Россия Федерациясе Конституциясенә туры килми дип тану өчен җитәрлек (1995 елның 25 апрелендәге 3-П номерлы, 2001 елның 5 июлендәге 11-П номерлы, 2004 елның 6 апрелендәге 7-П номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 43-П номерлы һ.б. карарлар).

Моннан тыш, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан дәгъва белдерелә торган Тәртиптә җирле үзидарә вәкаләтле органының өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарның җир кишәрлеген түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән законда билгеләнгән хокукый нормаларны үтәү буенча гамәлләре эзлеклелеген регламентлаштырганда җибәрелгән билгесезлек дәгъвалана торган хокукый җайга салуның җирле үзидарә органнарының бу мәсьәләдәге компетенциясеннән читкә чыгуына китергән.

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезләмәләре үзләренең эчтәлеге һәм мәгънәсе буенча шуны күздә тоталар: аларның күрсәтмәләрен үтәү өчен кабул ителә торган законга буйсынулы муниципаль норматив актта күпбалалы гаиләләр тарафыннан бер елдан да соңга калмыйча җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукы белән бәйле шартларга карата нинди дә булса хокук билгеләүче нормалар булырга тиеш түгел, чөнки закон чыгаручы җирле үзидарә органнарына аларны бирү процедурасын гына билгеләргә куша. Шул ук вакытта карала торган муниципаль норматив хокукый акт белән асылда күпбалалы гаиләләр тарафыннан исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукы эчтәлеге үзгәртелгән, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (икенче өлеш)

нигезләмәләренә туры килми, алар буенча җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирүнең законда каралган срогын алар бер мәртәбә: җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тарткан яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тарткан яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәгән очракта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәмәс өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 38 (беренче һәм өченче өлешләр) статьяларына туры килмиләр.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — гамәлдә булган хокукый җайга салуга күпбалалы гаиләләр тарафыннан исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыруның тиешле шартларын тәэмин итә торган үзгәрешләр кертергә кирәк.

Карала торган хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертелгәнче, хокук кулланучылар Татарстан Республикасы Конституциясенә, җир законнары нигезләмәләренә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән хокукый позицияләренә таянырга тиеш.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция

суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пунктын һәм II бүлегендәге 7 пунктын өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирүнең законда каралган срогын алар бер мәртәбә: җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тарткан яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тарткан яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәгән очракта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәмәс өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — гамәлдә булган хокукый җайга салуга күпбалалы гаиләләр тарафыннан исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыруның тиешле шартларын тәэмин итә торган үзгәрешләр кертергә кирәк.

Карала торган хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертелгәнче, хокук кулланучылар Татарстан Республикасы Конституциясенә, җир законнары нигезләмәләренә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән хокукый позицияләренә таянырга тиеш.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 80-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**